Газета 1931 елның
1 маеннан бирле чыга

Бу ни бу?! 2
Ветераннар тормышы. 3
Реклама.Котлаулар.Игъланнар. 4

Чүпрәле районы газетасы
(“Родной край” газета Дрожжановского района”)

# Туган як

җомга

**2 июнь, 2017 ел**

№ 39 (9175)

WWW.CHUPRALE-ONLINE.RU

3 июнь: яңгыр, җил төньяк-көнчыгыштан 8 м/с; температура +9, +5⁰. Кояш 03 сәг. 17 минутта чыга, 20 сәг. 18 минутта байый.

## КИЧӘ. БҮГЕН. ИРТӘГӘ.

### ТР Үзәк сайлау комиссиясе укулар үткәрә

2017 елның 23 маенда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе (ҮСК) участок сайлау комиссияләре әгъзалары өчен өстәмә укыту курсын гамәлгә ашыра башлады, ул Татарстан Республикасының һәр районында үткәреләчәк. Барлыгы 8 меңнән артык сайлауларны оештыручы белемнәрен күтәрәчәк. Беренчеләрдән булып укыту курсын Чүпрәле районы участок сайлау комиссияләре әгъзалары узды. Дәресләрне ҮСК секретаре Надежда Борисова үткәрде. Курс барышында сайлау законнарына кертелә торган үзгәрешләрне аңлатуга, шулай ук, 2017 елның 10 сентябрендә булачак бердәй тавыш бирү көненә әзерлек барышындагы килеп туган сорауларга аерым игътибар бирелде.

### Съезд эшендә район делегациясе катнашты

Казанда “Татарстан – Яңа Гасыр” республика иҗтимагый хәрәкәтенең VII съезды узды. Аның эшендә район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Айрат Җәлалов җитәкчелегендәге район делегациясе дә катнашты.
Программада соңгы өч еллык эшчәнлек буенча отчет тыңланды, хәрәкәт уставына үзгәрешләр тәкъдим ителде. Шулай ук, политсовет һәм контроль комиссиянең яңа составы расланды. “Татарстан – Яңа Гасыр” республика иҗтимагый хәрәкәтенең алдагы өч елга Политсовет рәисе итеп бертавыштан Фәрит Мөхәммәтшин, ә Айрат Җәлалов контроль комиссиясенең яңа составына сайланды.

### Санаулы көннәр калып бара

2017 елның киләсе яртыеллыгына газета-журналларга язылу чорының соңгы аена кердек. Хөрмәтле райондашларыбыз, димәк, газета-журналларга, шулай ук, район газетасы “Туган як”ка да язылуның санаулы көннәре калып бара. Исегезгә төшерәбез, “Татмедиа” басмаларына язылган абунәчеләребез төрле бүләкләр дә отарга мөмкин. Ашыгыгыз, язылып калыгыз, диясе килә. “Туган як”ка язылу бәясе –648 сум.

### “Урмай-зәлидә” фестиваленнән

Райондашыбыз Дарина Фәхретдинова шушы көннәрдә Чуашиядә узган “Урмай – зәлидә” халыкара фестивалендә катнашты һәм I дәрәҗәдәге Дипломга лаек булды. Милли мәдәниятне, традицияләрне саклауда керткән өлеше өчен Даринаның әнисе Венера ханым Фәхретдинова да фестивальнең Рәхмәт Хаты белән бүләкләнде.

### “Җылы йорт” Уби балалар приютында

Приютта попечительләр советының чираттагы утырышы булды. Беренче утырышта әлеге совет приютның эше һәм тормышы белән кызыксынган, гамәлгә ашырыла торган проектларны өйрәнгән иде. Икенче утырышта исә, Татарстан Республикасы буенча гамәлгә куелган балалар йортларына ярдәм проектына теләктәшлек итү буенча конкрет карарлар кабул ителде.
Балаларга чигү-тегү белән шөгыльләнү өчен тегү машиналарын “Чүпрәле элеваторы”, спорт мәйданчыклары җиһазларын “Ак Барс-Чүпрәле” һәм “Дементьев исемендәге агрофирма”сы алып бирәчәкләр. Приютка кирәк булган башка ял итү һәм уен җайланмалары да шәхси эшмәкәрләр иганәчелеге белән булдырылачак.
Район башлыгы Александр Шадриков исә приютка диван бүләк итәчәген белдерде.

## КӨН ВАКЫЙГАСЫ

# УНҖИДЕНЧЕ СПОРТ МӘЙДАНЧЫГЫ АЧЫЛДЫ







БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ. Автор фотосы.

**2017 ел – Уби авылы өчен чараларга бай ел булды. Әле күптән түгел генә биредә якташыбыз, ике тапкыр Советлар Союзы Социалистик Хезмәт Герое, тугыз тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән авиация промышленносте министры П.В.Дементьевның 110 еллыгын билгеләп үтсәләр, кичә урта мәктәп каршында төзелгән спорт мәйданчыгы файдалануга тапшырылды.**

Гөлия ФӘИЗОВА

Татарстан Республикасында гамәлгә ашырылган программалар нигезендә, соңгы елларда районыбызда бер-бер артлы шундый мәйданчыклар корыла башлады. Балаларга уйнарга, спорт белән шөгыльләнергә барлык җайланмалары булган бу мәйданчык районда– унҗиденче.

Уби авылы, бигрәк тә балалары өчен шатлык булган бу вакыйга тантаналы төстә, кунаклар катнашында үтте. Спорт мәйданчыгын 1 июнь– Халыкара балаларны яклау көнендә ачу тантанасы аерым төс өстәде.
Аны ачканда район башлыгы **Александр ШАДРИКОВ:**
–Балалар һәм яшьләр өчен төзелгән бу мәйданчык аларның яраткан урынына әйләнер дип ышанабыз. Алар биредә шөгыльләнеп физик яктан чыныксыннар, исәнлекләрен ныгытсыннар. Мәйданчык беркайчан да буш тормасын иде,- дигән теләк белдерде.
Авыл җирлеге башлыгы Алексей Ярухин авылга шундый бүләк ясаганнары өчен республика һәм район җитәкчеләренә рәхмәтләрен җиткерде. Ул мәйданчыкны саклап тотарга һәм максатчан файдаланырга ышандырды.
Чарада мәктәп укучылары эчтәлекле монтаж белән чыгыш ясадылар. Һәм спорт өлкәсендә уңыш яулаган Уби урта мәктәбе укучылары бүләкләнде.